Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының илленче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

27 декабрь, 2024 ел № 377

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә, 2024 елның 3 маендагы гавами тыңлаулар беркетмәләрен һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2021 елның 8 июлендәге 85 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлегенең Генераль планына (Советның 2023 елның 22 февралендәге 215 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләре белән) электрон чыганактагы кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru/) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында әлеге карарны кертергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов